КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 23 гыйнвар г.Казань № 34

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының төбәк этапларын Татарстан Республикасында уздыру турында» 2025 ел, 27 июнь, 470 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының төбәк этапларын Татарстан Республикасында уздыру турында» 2025 ел, 27 июнь, 470 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2024 елның 23 декабреннән» сүзләрен «2025 елның 22 октябреннән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ һәм $2^2$ пунктлар өстәргә:

«$2^1$. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Бөтенроссия конкурсының төбәк этапларын оештыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия бирү өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең төп администраторы булып тора;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы Бөтенроссия конкурсының төбәк этапларын оештыру чараларын гамәлгә ашыру өчен каралган бюджет чараларының төп идарәчесе булып тора.

$2^2$. Бөтенроссия конкурсының төбәк этапларын үткәрүне финанслау Татарстан Республикасы бюджеты һәм Бөтенроссия конкурсының төбәк этапларын оештыруга юнәлдерелгән чараларны финанс белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидия исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

түбәндәге эчтәлекле 4[1] пункт өстәргә:

«4[1]. Бөтенроссия конкурсының төбәк этапларын оештыру һәм үткәрү буенча операторга, Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этапларын оештыру буенча оештыру-техник тәэмин итү һәм эшне координацияләү өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнарына, Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы башланганчы 10 календарь көннән дә соңга калмыйча:

Бөтенроссия конкурсының төбәк этапларын оештыру һәм үткәрү, шулай ук ведомствоара нәтиҗәле хезмәттәшлекне тәэмин итү өчен тиешле ведомстводан җаваплы координаторлар билгеләргә;

Бөтенроссия конкурсының төбәк этапларында катнашучыларны сынаулар үткәрү өчен эш мәйданчыкларын билгеләргә һәм әзерлекне тәэмин итәргә;

сайланган эш мәйданчыкларын әзерләргә һәм тиешле җиһазлар һәм материаллар белән җиһазларга, аларның техник әзерлеген тәэмин итәргә, шулай ук гамәлдәге санитар һәм янгын куркынычсызлыгы нормаларына тулысынча туры килүен тәэмин итәргә.»;

түбәндәге эчтәлекле 5[1] пункт өстәргә:

«5[1]. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 298 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясенең «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» Россия Федерациясе дәүләт программасына 33 нче кушымтада китерелгән «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль һәм төбәк этапларын оештыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 9 пункты нигезендә «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этабын уздыру урынына бару һәм даими яшәү урынына кайту өчен Бөтенроссия конкурсының төбәк этабында беренче урынны алган катнашучының транспорт чыгымнарын финанслауны тәэмин итәргә.»;

әлеге карар белән расланган «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының төбәк этапларын Татарстан Республикасында уздыруны әзерләүне һәм уздыруны оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составыннан А.И.Поминовны, А.А.Сабированы чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Хәдиуллин Илсур Гәрәй улын | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын, оештыру комитеты рәисе урынбасарын |
| Галиев Тимур Мирзанур улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгын |
| Сафиуллина Лилия Корбан кызын | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрының беренче урынбасарын |

әлеге карар белән расланган «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының төбәк этапларын Татарстан Республикасында оештыру буенча оештыру-техник тәэмин итү һәм координацияләү өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 27 июнь, 470 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 23 гыйнвар, 34 нче
карары редакциясендә)

«Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының төбәк этапларын Татарстан Республикасында оештыру буенча оештыру-техник тәэмин итү һәм координацияләү өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары

| Т/с | Номинация[1] | Конкурсны үткәрүне оештыру-техник тәэмин итү һәм конкурсны оештыру буенча эшне координацияләү өчен җаваплы республика башкарма хакимияте органы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Даими номинацияләр | | |
| 1. | Агроном | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| 2. | Икенче старт (махсус номинация) | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| 3. | Ташчы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 4. | Эшкәртү эшләре мастеры | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 5. | Бульдозер машинисты | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 6. | Экскаватор машинисты | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 7. | Механизатор | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |

[1]Номинацияләр исемлеге «Һөнәре буенча иң яхшы» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсын уздыру буенча оештыру комитетының 2025 елның 22 октябрендәге 2бр номерлы утырышы беркетмәсе белән расланды.

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 8. | Радиоэлектрон аппаратура монтажчысы | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 9. | Программа белән идарә ителә торган станоклар операторы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 10. | Пешекче | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| 11. | Эретеп ябыштыручы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 12. | Слесарь-җыючы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 13. | Сыр кайнату өлкәсендә азык-төлек сәнәгате технологиясе | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| 14. | Токарь | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 15. | Фрезерчы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 16. | Тегүче | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| Ротацияләнә торган номинацияләр | | |
| 1. | Ветеринария фельдшеры | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе |
| 2. | Робототехника буенча белгече | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы |
| 3. | Пилотсыз авиация системаларын эксплуатацияләү буенча белгеч | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы |
| 4. | Электромонтер | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| Бюджеттан тыш номинацияләр | | |
| 1. | Газорезчик | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| 2. | Транспорт куркынычсызлыгы инспекторы | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы |
| 3. | Йөк машинасы һәм пассажир хәрәкәте машинисты | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 4. | Техник-протезист | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |